КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2025 ел, 8 август г.Казань № 580

Нурлат шәһәрендә 2024 елның 6 апрелендә күпфатирлы йортта газ-һава катнашмасы шартлау нәтиҗәсендә һәлак булган А.И.Антошкина гаиләсе әгъзаларына бер тапкыр матди ярдәм күрсәтү турында

Нурлат шәһәрендә 2024 елның 6 апрелендә күпфатирлы йортта газ-һава катнашмасы шартлау нәтиҗәсендә һәлак булган А.И.Антошкина гаиләсе әгъзаларына бер тапкыр матди ярдәм күрсәтү максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына Нурлат шәһәрендә 2024 елның 06 апрелендә күпфатирлы йортта газ-һава катнашмасы шартлау нәтиҗәсендә һәлак булган А.И.Антошкина гаиләсе әгъзаларына (иренә, балаларына, ата-анасына һәм аның тәрбиясендә булган затларга), гаиләнең һәр әгъзасына 1 000,0 мең сум күләмендә, бер мәртәбә матди ярдәм түләргә.

2. Әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән чыгымнарны финанс белән тәэмин итү чыганагы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының резерв фонды акчалары булуын билгеләргә.

4. Карарга теркәлгән Нурлат шәһәрендә 2024 елның 6 апрелендә күпфатирлы йортта газ-һава катнашмасы шартлау нәтиҗәсендә һәлак булган А.И.Антошкина гаиләсе әгъзаларына бер тапкыр матди ярдәм түләү тәртибен расларга.

5. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин